ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.08.2024 ел Баулы шәһәре №118

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының 2019 елның 15 мартындагы 67 номерлы бюджетына административ комиссия тарафыннан салынган, административ штрафларны түләү буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү Тәртибенә (2020 елның 24 апрелендәге 88 номерлы, 2020 елның 20 июлендәге 147 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясе аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 22 июлендәге 194-ФЗ номерлы Федераль законына ярашлы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының 2019 елның 15 мартындагы 67 номерлы бюджетына административ комиссия тарафыннан салынган, административ штрафларны түләү буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү Тәртибенә (2020 елның 24 апрелендәге 88 номерлы, 2020 елның 20 июлендәге 147 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

2.1. пунктында:

б) пунтчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) гражданинның, шәхси эшмәкәрнең банкротлык процедураларын, 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы «Бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшү турында» Федераль законына ярашлы тәмамлау - күрсәтелгән Федераль закон нигезендә бюджетка түләүләр буенча ул түләү бурычын үтәүдән азат ителгән бурыч өлешендә,;»;

д) пунтчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) «Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтарганда, әгәр бурыч барлыкка килгән көннән бурычлыга карата бөлгенлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаса, башкаручы суд приставы тарафыннан башкару эшен тәмамлау турында карар чыгарылганда банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен биш елдан артык вакыт узган булса;»;

ж) пунктчасы белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«ж) банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип тану яки банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турында гаризаны суд тарафыннан кире кайтару турында акт кабул ителгәндә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарны контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров